# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ
**(III чакырылыш)**

егерме бишенче утырыш

## КАРАРЫ

13 декабрь 2018 ел **№ 158** Теләче авылы

«2018-2020 елларга Теләче муниципаль районында терроризм һәм экстремизмны профилактикалау» программасын гамәлгә ашыру барышы турында

Теләче муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе И.В. Мөбиновның «Теләче муниципаль районында 2018-2020 елларга терроризмны һәм экстремизмны профилактикалау программасын гамәлгә ашыру барышы турында» мәгълүматын тыңлаганнан соң, Теләче муниципаль районы Советы **карар кабул итте**:

1. Теләче муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе И.В.Мөбинов мәгълүматын игътибарга алырга.
2. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы башкарма комитетына «2018-2020 елларга Теләче муниципаль районында терроризм һәм экстремизмны профилактикалау» программасын үтәү буенча планлы эш оештырырга.
3. Теләче муниципаль районы территориясендә эшчәнлек алып баручы предприятие, оешма, учреждениеләрнең хезмәт коллективларына, шәхси эшмәкәрләргә «2018-2020 елларга Теләче муниципаль районында терроризмны һәм экстремизмны профилактикалау» программасының тиешле пунктларын үтәү буенча эшне оештырырга тәкъдим итәргә.
4. Теләче муниципаль районы территориясендә эшчәнлек алып баручы дини оешмаларга үз эшчәнлекләрендә «2018-2020 елларга Теләче муниципаль районында терроризм һәм экстремизмны профилактикалау» программасын куллануны тәкъдим итәргә.
5. Россия Эчке эшләр министрлыгының Теләче муниципаль районындагы бүлекчәсенә программа кысаларында профилактик чаралар үткәргәндә җирле үзидарә органнарына методик ярдәм күрсәтүне тәкъдим итәргә.
6. Җирле массакүләм мәгълүмат чараларында программа чараларының үтәлешен яктыртуны «Татмедиа» АҖнең Теләчеинформ филиалына тәкъдим итәргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль район Советының законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасын үтәү буенча комитетына йөкләргә.

Теләче муниципаль
районы башлыгы И.Ф. Зарипов